# РАЙОННЫҢ СОЦИАЛИСТИК ХЕЗМӘТ ГЕРОЙЛАРЫ



## Хәстиев Мирбат Бәдри улы

*(1927-2000)*

Хәстиев Мирбат Бәдри улы 1927 елның 7 июлендә Арча районы Казанбаш авылында туган. Ул авыр сугыш елларында көч җитмәстәй ирләр хезмәтен үз җилкәсенә алган малайларның берсе була.

Ә аның язмышын бер очраклы хәл билгеләгән. 1951 елда районнан авыл хуҗалыгы кадрлары әзерләү буенча икееллык мәктәпкә бер кеше җибәрергә кирәк була. Шунда кемдер Казанбаш урта мәктәбе директоры, Ленин ордены кавалеры Бәдри Хәстиевнең улы армиядән кайту турында искә төшерә. Егет бик тырыш, эшчән, нәкъ әтисенә охшаган. Кырда да, умарталыкта да эшләгән. Киләчәктә колхоз рәисе булырга аннан да лаеклы кем бар? Әлеге мәктәпне тәмамлагач, Мирбат Бәдри улы 1953 елда туган хуҗалыгында җитәкче була. Соңрак, читтән торып, авыл хуҗалыгы институтын тәмамлый. Ул Арча районының "Известия" колхозы рәисе булып 1986 елның июненә кадәр эшли. Аның җитәкчелегендә хуҗалыкның икътисады елдан-ел ныгый. XI бишьеллыкка ит җитештерү 2 тапкырдан күбрәккә, сөт җитештерү 3 тапкырга арта. Бөртеклеләр уңышы 8 центнердан 24 центнерга күтәрелә. Рентабельлек 50 процентка якынлаша. Аннан соңгы елларда да колхозның икътисады ныгый бара.

Ул елларда "Известия" колхозының үзәк утарында гына түгел, ә кечкенә авылларда да күп төзиләр. Менә дигән мәдәният йортлары, клублар, мәктәпләр, балалар бакчасы, кибетләр калкып чыга. Ел саен уннарча гаилә өй туйлары уздыра. Хуҗалык биналары да яңартыла, хезмәт шартлары яхшыра. Мәсәлән, терлекчелектә ике смена кертелә.

Ел саен хуҗалык югары уку йортларына, техникумнарга үз стипендиатларын җибәрә. Шуңа күрә хуҗалыкта барлык белгечләр дә үз егетләре һәм кызлары була. Хуҗалык рәисе булып эшләү чорында М.Хәстиев бик күп бүләкләргә лаек була. Шулардан иң зурлары – Ленин һәм Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары. Ә 1984 елның декабрендә аңа Социалистик Хезмәт Герое исеме бирелә.

М. Хәстиев Бөтенроссия колхозлар советы әгъзасы, район Советы депутаты булып сайлана. Вафатына кадәр (2000 елның 14 июле) ул авылдашлары өчен бик күп изгелекләр эшләде.



## Сәгъдуллин Шәрифулла Сәгъдулла улы

*(1930-2001)*

Ул 1930 елның 29 июлендә Арча районының Шушмабаш авылында туа. Аның балалык һәм яшьлек чоры авыр сугыш елларына туры килә. Авылдагы барлык хезмәт хатын-кызлар, балалар җилкәсенә төшә. Шәрифулла да 12 яшеннән "Шушма" колхозында эшли башлый..

1952 елда егетне Совет Армиясенә алалар. Ватан алдындагы изге бурычын үтәп кайткач, Үрнәктәге училищеда укып, механизатор һөнәре ала һәм ул 1991 елга кадәр шушы һөнәренә турылыклы булып кала.

Чирәм җирләрне күтәрү хәрәкәте башлангач, Шәрифулла Сәгъдуллин кебек тырыш, намуслы, илнең чын патриоты булган кешеләр беренчеләрдән булып Казахстанга юл тоттылар, илне икмәкле итү өчен, үзләреннән зур өлеш керттеләр.

Казахстан далаларыннан чыныгып кайткан механизатор 1959 елдан – "Северный" совхозында. Ул, туган як кырларын иңләп, сокландыргыч нәтиҗәләргә ирешә, район механизаторлары арасындагы ярышны озак еллар буена әйдәп баручы булды.

Якташыбызның фидакарь хезмәтен илебез югары бәяләде. 1976 елда ул иң зур бүләк – Социалистик Хезмәт Герое исеменә лаек булды. Аңа Ленин ордены, "Урак һәм Чүкеч" алтын медале тапшырылды. Ул Татарстан Югары Советының X чакырылыш депутаты итеп сайланды, "Сугыш елларындагы фидакарьлеге өчен" медале белән бүләкләнде.

Шәрифулла Сәгъдулла улы Сәгъдуллин – районыбызның горурлыгы. Гаять тыйнак, тәртипле, киң күңелле бу кеше бик күп яшьләрнең игелекле остазы булды. Район механизаторлары иген игү серләренә аннан өйрәнделәр. Ул һәрвакыт киңәш бирергә, ярдәм итәргә омтылды.

Лаеклы ялга чыккач та ул тракторда эшләвен дәвам итте, туган ягының чын патриоты булды, җәмәгать тормышында актив катнашты...

Чын игенче, фидакарь хезмәт кешесе Сәгъдуллин Шәрифулла Сәгъдулла улының якты истәлеге халык күңелендә озак яшәр, аның исеме онытылмас.

## Галимова
## Дания Һадиҗан кызы

*(1932)*



Галимова Дания Һадиҗан кызы 1932 елда Арча районының Мирҗәм авылында туган. Ул характерын әнисеннән алган бугай. Әнисенә тормыш ачысын күп татырга туры килә. Ул кече яшьтән ятим калган энеләрен тәрбияли. 16-18 яшькә җиткәч, алар гражданнар сугышына китәләр һәм кире әйләнеп кайтмыйлар.

Даниянең дә балачагы җиңел булмый. Ул Бөек Ватан сугышы чорына туры килә. Ә 1947 елда аңа, 15 яшьлек кызга, тайлар карауны тапшыралар. Ул чорда ничә яшьтә булуны сорап тормыйлар, эшнең авырлыгы турында да әйтмиләр. Чөнки күп ирләр фронттан әйләнеп кайтмый һәм эшче куллар җитешми.

Дуңгызчылык фермасы оештырылгач, Данияне шунда җибәрәләр. "Кирәк икән, эшләрмен", – дип җавап бирә ул. Татар авылы өчен бу терлекчелекнең бөтенләй яңа тармагы була. Ул чакта, 1957 елда, эш әле механикалаштырылмый. Шулай да Дания Һадиҗан кызының зур тырышлыгы һәм эшкә җаваплы каравы аркасында, әйбәт нәтиҗәләргә ирешелә. Тырыш кызны "Ватан" совхозында гына түгел, бөтен Арча районында мактап телгә ала башлыйлар.

1966 елда аны "Почет билгесе" ордены, ә ТАССРның 50 еллыгы уңаеннан һәм терлекчеләр ярышында җиңүләре өчен, республика Югары Советы Президиумының Мактау грамотасы белән бүләклиләр.

VIII бишьеллык планны үтәү нәтиҗәләре буенча, СССР Югары Советы Президиумының 1971 ел, 8 апрель Указы белән Дания Һадиҗан кызы Галимовага Социалистик Хезмәт Герое исеме бирелә, Ленин ордены, "Урак һәм Чүкеч" алтын медале тапшырыла.

1987 елга кадәр "Ватан" совхозында дуңгыз караучы булып эшли.

## Әсхәдуллин
## Галимулла Әсхәдулла улы

*(1928)*



Әсхәдуллин Галимулла Әсхәдулла улы 1928 елның 14 апрелендә Арча районы Мирҗәм авылында туган. Җидееллык мәктәпне тәмамлагач, 1942 елда колхозда эшләргә керешә. Дошманны җиңүгә үзеннән күбрәк өлеш кертү өчен, иң авыр эшләргә үзе теләп алына. 1947 елда балта остасы һөнәрен үзләштерү теләге белән, Казандагы ФЗО мәктәбенә керә. Әмма мәктәптә, синдәй таза, нык егеткә металл белән эш итү кулайрак, дип киңәш итәләр. Шулай итеп, фрезерчы һөнәре аның бөтен гомеренә сайлап алынган булып чыга.

Ул Горбунов исемендәге Казан авиация житештерү берләшмәсендә 1989 елга кадәр эшли. Эшен армия хезмәте генә бүлеп тора. Хезмәттән аерылмыйча гына өч еллык мастерлар мәктәбен тәмамлый. Заводта иң яхшы эшчеләрнең берсенә әверелә. Зур җаваплылык хисе тоеп эшләве, пөхтәлеге белән аерылып тора. Ул инструментларны, төрле җайланмаларны даими рәвештә камилләштерә. Үз эшендә осталыкның иң югары ноктасына ирешә. Предприятиедә аның иҗат мәктәбе булуын, өйрәнергә теләге булган һәркемгә анда ишек һәрвакыт ачык булуын яхшы беләләр. Г.Әсхәдуллин хезмәт шартларын яхшырту, металларны сак файдалану, житештерүчәнлекне күтәрү, продукциянең сыйфатын яхшырту буенча 29 рационализаторлык тәкъдиме кертә һәм үзе үк аларны тормышка ашыра. Партия Өлкә комитеты бюросында Г.Әсхәдуллин тәҗрибәсен хуплап, аны һәр эшчеләр коллективында тормышка ашыру турында махсус карар кабул ителә.

Хезмәттәге зур казанышлары өчен Галимулла Әсхәдулла улы Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр, мактау грамоталары белән бүләкләнә. 1974 елның 16 гыйнварында аңа Социалистик Хезмәт Герое исеме бирелә. Г.Әсхәдуллин СССР Югары Советы депутаты итеп сайланды, КПССның шәһәр һәм өлкә комитетлары әгъзасы, сугыш һәм хезмәт ветераннарының республика советы президиумы әгъзасы булды.

...Зәңгәр күктә көмеш канатлы пассажир авиалайнерлары тавышын ишетсә, ул аларның очышын карамыйча калмый. Алар белән Галимулла Әсхәдулла улының бөтен гомере бәйләнгән.

## Габдрахманова Стелла Зәки кызы

*(1933)*



Габдрахманова Стелла Зәки кызы 1933 елның 17 ноябрендә Казанда туган. Аның әнисе укытучы булып эшли, әтисе Татарстан китап нәшриятында җитәкче эштә була.

Кызга әти-әнисеннән аерылырга туры килгәч, Стелланы Арча районының Кышлау авылында укытучы булып эшләүче әбисе үз янына ала. Стелла шул чакта үз язмышын шушы төбәк белән бәйләр, үзенең бәхетен биредә табар дип уйладымы икән?

Арчада мәктәпкә укырга керә. Бу сугыш еллары була. Кәгазь, дәфтәр, дәреслекләр җитешми. Керосин лампасы, чыра уты яктысында дәрес әзерләргә туры килә. Әмма белемгә омтылыш көчле була шул. Стелла Зәки кызының педагог-фронтовиклар, аеруча РСФСРның атказанган укытучысы, рус теле һәм әдәбияты укытучысы Л.Преображенская сөйләгәннәрне һич онытасы юк. Ул камалыштагы Ленинградтан эвакуация белән кайткан була.

1955 елда Казан дәүләт педагогия институтын тәмамлагач, аны Арча районының Яңа Кенәр урта мәктәбенә эшкә җибәрәләр. Кызга бу төбәк яхшы билгеле була. Авырлыкларны да яхшы белә: автобуслар да йөрми, ичмаса, бирегә...

Әмма яшь укытучы авырлыклардан курыкмый, гомер буена шушы төбәктә балалар тәрбияләргә кала.

Тормыш аның күз алдында үзгәрә. Авылның үсүенә, авыл хуҗалыгының ныгуына аның укучылары да зур өлеш кертә. Чөнки укытучылары аларда рус теле һәм әдәбиятына гына түгел, туган җирләренә олы мәхәббәт тә тәрбияли.

1971 елда С.Габдрахманова "Почет билгесе" ордены белән бүләкләнә. Ә 1978 елның 27 июнендә яшь буынга белем бирүдәге һәм тәрбияләүдәге зур уңышлары өчен аңа Социалистик Хезмәт Герое исеме бирелә.

Стелла Зәки кызы авылда озак еллар җәмәгать эше алып барды, профсоюзлар өлкә комитеты әгъзасы итеп сайланды. Аның күп укучылары остазлары юлыннан киттеләр.

## Шәйхетдинов Илсур Гарәфи улы

*(1936)*



Шәйхетдинов Илсур Гарәфи улы 1936 елның 2 гыйнварында Арча районы Өрнәш авылында күп балалы укытучы гаиләсендә туа. Арча педагогия училищесын тәмамлый. Комсомол юлламасы белән механизация училищесына барып керә. Арча МТСында эшли. 1957-1960 елларда армиядә хезмәт итә. 1960 елның декабрендә "Татнефтепроводстрой" трестының 3 нче төзү-монтаж идарәсендә бульдозерчы булып эшли башлый. Аннары Чиләбегә торба салучы кран машинисты һөнәрен үзләштерергә җибәрелә. Укуын тәмамлагач, бригадир итеп билгеләнә. Ике елдан аны колонна начальнигы, тагын ике елдан участок җитәкчесе итеп билгелиләр. Бераздан ул торбаүткәргечләр төзелеше идарәсе башлыгы, аннары генераль директор урынбасары була.

Озак еллар хезмәт чорында Илсур Гарәфи улы йөзләрчә чакрым тайга урманнары, Себер сазлыклары аша уза. Торбаүткәргечләрне Краснодар краенда, Калмык Республикасында, Украинада да сузарга туры килә. 1966 елда Шәйхетдинов иң беренче бүләген – Ленин ордены ала. Аның бригадасы Поляр Төньяк белән чиктәш районда сазлыклар аша үзенең беренче нефтьүткәргечен суза. Коллектив беренче тапкыр буларак зур диаметрлы торбаларны эретеп ябыштыру ысулын куллана. Шаим-Төмән торбаүткәргечен салучы Шәйхетдинов бригадасы үрнәген башкалар да файдалана башлыйлар. Төмән өлкәсенең төньягыннан Уралга һәм Үзәккә 1973-1974 елларда газүткәргеч төзү аның хәтерендә мәңге саклана. Шәйхетдинов бригадасы үз участогында эшне билгеләнгән вакыттан биш айга алдан тәгаллый. Ярышның төп инициаторы Шәйхетдинов 1975 елда моның өчен Социалистик Хезмәт Герое исеменә лаек була. "Татнефтепроводстрой" трестының Шәйхетдинов җитәкчелегендәге идарәсе, Ужгород юнәлешендә 820 км озынлыктагы торбаүткәргечне сузганда, рекордлы күрсәткечкә ирешә. Аның тарафыннан беренче тапкыр комплекслы-технологик агым ысулы тормышка ашырыла. 1983 елда Илсур Гарәфи улы Октябрь Революциясе ордены белән бүләкләнә. Шәйхетдинов белән янәшә аның биш бертуганы, шулай ук улы да эшлиләр. Шәйхетдиновлар династиясенең "Татнефтепроводстрой" трестындагы гомуми эш стажы 170 елга тигез.